ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«29» июня 2026 ел № 537

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә сайлау участоклары төзү турында” 2025 елның 30 маендагы 548 нче карарына үзгәрешләр кертү турында**

Сайлау участогы бинасын алмаштыруга бәйле рәвештә “Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә сайлау участоклары төзү турында” 2025 елның 30 маендагы 548 нче карарына үзгәрешләр кертергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**981 нче сайлау участогы**

Үзәк: Венета авылы, Яшьләр урамы, 5/1 йорт, фельдшер-акушерлык пункты бинасы.

Телефон: 3-06-09.

Сайлау участогы чикләренә түбәндәгеләр керә: Венета, Еромоловка, Красная Горка, Михайловка, Платоновка авыллары, Ашабаш авылы территориясенең бер өлеше: Яңа ур., Аркылы ур., Күпер ур., 1нче йорттан алып 17нче йортка кадәр.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкче Л.И. Абдуллин